ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2023 г. Казань № 424-42/кс-2023

«Татнефть-АЗС Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Чаллы филиалы өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2024-2028 елларга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 08.12.2023 № 53-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татнефть - АЗС Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Чаллы филиалы (алга таба – «Татнефть - АЗС Центр» ҖЧҖ Чаллы филиалы) өчен әлеге карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, эчә торган суга һәм ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Татнефть - АЗС Центр» ҖЧҖ Чаллы филиалы өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2024-2028 елларга, әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Татнефть - АЗС Центр» ҖЧҖ Чаллы филиалы ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26

гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2023 № 424-42/кс-2023
карарына 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Татнефть - АЗС Центр» ҖЧҖ Чаллы филиалы өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Тукай муниципаль районы | | | |
| 1 | «Татнефть - АЗС Центр» ҖЧҖ Чаллы филиалы (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 12,87 | 16,48 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 14,85 | 18,53 |
| | | 01.01.25 башлап 30.06.25 кадәр | 14,36 | 18,21 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 14,36 | 18,21 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 14,36 | 18,21 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 15,30 | 19,38 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 15,30 | 19,38 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 15,34 | 19,43 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 15,34 | 19,43 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 16,31 | 20,63 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2023 № 424-42/кс-2023
карарына 2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Татнефть - АЗС Центр» ҖЧҖ Чаллы филиалы өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2024-2028 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны хәл итүче оешма исеме, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Татнефть-АЗС Центр» ҖЧҖ Чаллы филиалы | | | | | | |
| 1.1 | Эчәргә яраклы су | 2024 | 664,53 | х | - | - | 0,44 |
| | | 2025 | х | 1 | - | - | 0,44 |
| | | 2026 | х | 1 | - | - | 0,44 |
| | | 2027 | х | 1 | - | - | 0,44 |
| | | 2028 | х | 1 | - | - | 0,44 |
| 1.2 | Ташландык су агызу | 2024 | 788,94 | х | - | х | 0,30 |
| | | 2025 | х | 1 | - | х | 0,30 |
| | | 2026 | х | 1 | - | х | 0,30 |

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны хәл итүче оешма исеме, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Норматив табыш дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| | | 2027 | х | 1 | - | х | 0,30 |
| | | 2028 | х | 1 | - | х | 0,30 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге